СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

28 март, 1997 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. № 34 (8046) Бәясе билгеләнгәнчә

## 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

## ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ ӨМЕТЛӘНЕП

Елаур төбәге гомер - гомергә игътибардан читтә кала килде. Торак пунктларның район үзәгеннән шактый ерак урнашуы, туфрагының чагыштырмача уңдырышсыз, шуның нәтиҗәсендә продукция җитештерүнең түбән булуы да сәбәп булгандыр моңа. Хәер, батканны батыру җиңел эш бит ул. Ә авыр чакта үзвакытында эшлекле ярдәм күрсәтелсә, бәлки алар да бераз мантыган булыр иде. Районыбызның яңа җитәкчелегенең элеккеге «Знамя Октября» КХАсын (хәзер «Төзүче») - МСОга, «Мамык»ны РСУга ярдәмче хуҗалык итеп тапшыруына ук уңай якка үзгәрешләр сизелде бит. Хуҗалыкларның беренчесендә һәр сыердан савылган тәүлеклек сөт узган елның шул чорындагыдан 2, «Мамык»та исә 4 килограммга күбрәк. Хуҗалыкларның һәр икесендә дуңгызчылыкны үстерүгә дә ныклы нигез салынып килә. Күзгә бәрелеп торырлык башка үзгәрешләр дә бар. Узган сишәмбедә Елаур авыл клубында шушы төбәктә яшәүчеләр белән очрашуы вакытында 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат, район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да шуларны ассызыклап, төбәктәге хуҗалыкларны күтәрүгә булышлык итүне намус эше санаячагын әйтте. Хуҗалыкларның потенциаль мөмкинлекләрен анализлап ул: «Киләчәктә бу төбәк чәчәк атарга тиеш», диде. Әлеге куст торак пунктларын газлаштыру буенча фикерләрен дә уртаклашты ул. Газлаштыру буенча элеккеге план үзгәргән, хәзер аны Әлки районы аркылы түгел, ә торбаларны Чулпан авылы аша сузу отышлы булуын әйтте. Һәм авыл өчен мөһим бу проблема өстендә үзенең дә туктаусыз эшләячәгенә ышандырды.

Шәхси хуҗалыкларда малларның баш санын арттыру халыкның тормыш - көнкүреш хәлен яхшыртуда мөһим алшарт булуын искә алып, район хакименең халыкка авыл җирендә маллар асрауны җиңеләйтү өчен дә булышлык итәчәген ассызыклавын халык алкышлап кабул итте.

Гомумән, җыелыш күтәренке рухта барды. Залдагылар депутатлыкка кандидатның ышанычлысы - Октябрь урман хуҗалыгы директоры Ф.М.Минсәлимовның Ф.С.Сибагатуллинның тормыш һәм хезмәт юлы белән таныштыруын кызыксынып тыңладылар, «Төзүче» ярдәмче хуҗалыгы хуҗасы Ә.М.Йосыпов, МСО начальнигы Н.Б.Мөлековның депутатлыкка кандидатны яклап чыгыш ясауларын хуплап каршыладылар һәм 30 март - сайлаулар көнендә аны яклап тавыш бирәчәкләренә ышандырдылар.

Р.ГИНЯЕВА.

*Матбугат - 97*

## «Дуслык»ка льготалы язылу!

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

Без сезнең үз район газетагызы якын күреп, аны даими алдыруыгызга бик шатбыз. Заманаларның катлаулы һәм авыр булуына да карамастан, «Дуслык» ның тиражы тотрыклы тору, аңа ел дәвамында да язылучылар байтак булуы безне икеләтә куандыра. Бүген безнең газетаны шәһәрдә һәм авылларда ун меңгә якын гаиләдә алдыралар.

Һәм бүген, 1997 елның икенче яртысы өчен вакытлы матбугатка массовый төстә язылу кампаниясе башланырга торганда без Сезгә, газетабызның даими укучыларына мөрәҗәгать итәбез. 1 апрельдән элемтә бүлекләренә килеп, матбугат басмаларына язылганда без Сезнең иң беренче бланкларны «Дуслык»ка дип тутырачагыгызга шикләнмибез. Шунысын да әйтик, редакция, район элемтә узелы белән килешеп, район газетасына ярты елга язылу бәясен элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калдырды. Бу хакта үзегез күргән - белгәннәрнең моңарчы безнең газетаны алдырмаганнарына да җиткерерсез дип уйлыйбыз.

**Һәм, иң мөһиме!**

**Апрельнең 1еннән 10сына кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына льготалы бәягә, ягъни 16.200 сумга гына язылып калырга мөмкин. Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да бу инициативабызны хуплады.**

**Атнасына өч көн чыга торган матбугат органына язылуның шуннан да арзанрак бәясенең әле беркайда да булганы юк. Шулай булгач, нибары 16.200 сум акчагызны кызганмыйча, район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышандырабыз.**

**Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!**

## *Күмәк эшчәнлек хакына*

***25 мартта, сишәмбе көнне Ф.С.Сибагатуллин «Норлатнефть» нефть - газ чыгару идарәсенең ике меңгә якын эшләүчене берләштергән коллективы вәкилләре белән очрашты.***


Шунысы игътибарга лаек, башка хезмәт коллективларында узган гадәти сайлау алды очрашуларыннан аермалы буларак, биредә беренче минутлардан ук иркен һәм ачыктан - ачык сөйләшүгә этәрә торган атмосфера урнашты. Анысы кара алтын чыгаручыларның хакимият башлыгы белән күптән көтелгән беренче очрашуы булудан да шулай килеп чыккандыр дип уйларга кирәк. Ул уңайдан Фатих Сәүбәнович үзе: «Бүген иртән мин Елаур халкы янында булдым. Килеп эшли башлаганнан соң инде алтынчы тапкыр баруым, чөнки беләм - мин анда кирәгрәк. Ә куәтле җитештерү потенциалына ия сезнең коллективыгыз үз алдында торган җитештерү программасын үзе дә уңышлы гына хәл итеп килә...» диде.

Аннары сүз бүгенге көнебез һәм киләчәккә перспективаларыбыз турында барды. Хакимият башлыгы тотрыклы эшләүләре, шактый ук үскән инфраструктура булдырулары, алар килгәнчегә кадәр районның перспективасыз дип саналган авыллары язмышына дучар ителгән Әхмәт авылын үз балансларына алып аны яңадан торгызуга күп көч куйганнары өчен нефтьчеләргә рәхмәт белдерде һәм район киләчәктә дә шәһәр һәм авылларның алдагы социаль үсеше проблемаларын хәл итүдә нефтьчеләрнең практик ярдәменә өметләнәчәк дип басым ясап әйтте. «Су, газ, төзекләндерү, эшләүче халыкның тормыш - көнкүреш шартларын яхшырту - җитештерүгә бәйле мәсьәләләр белән беррәттән әнә шулар турында да барыбыз бергәләп кайгыртырга туры киләчәк», диде Ф.С.Сибагатуллин.

Билгеле, ул үзенең чыгышында авыл хуҗалыгына кагылышлы мәсьәләләрне дә читләтеп үтмәде, аерым алганда сөт җитештерү өлкәсендәге алга китеш турында әйтеп, авылда җитештерү мөнәсәбәтләрен реформалауның барышы турында сөйләде. Нефтьчеләр депутатлыкка кандидатны зур игътибар белән тыңладылар.

( Ахыры 3 нче биттә).

## КҮҢЕЛЛЕ КИЧТӘ МӘГЪНӘЛЕ ОЧРАШУ



Район мәдәнияты йортының бу кадәр халыкны күптән үзенә җыйганы юк иде. Залдагылар-50 нче номерлы Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат, район хакимияте башлыгы Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин белән очрашуга килүчеләр арасында чал чәчле өлкәннәр дә, яшь җилкенчәк тә бар иде.

Очрашуны Норлат җирле үзидарә Советы рәисе Ф.И.Гайнуллин ачты. Депутатлыкка кандидатның ышанычлысы Л.Н.Газизуллинаның кыскача таныштыру чыгышыннан соң халык каршына Фатих Сәүбәнович үзе чыкты. Кыска, шул ук вакытта эшлекле һәм конкрет бу аралашу кандидатның халык мәнфәгатен нык якларлык, аның ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерерлек тәҗрибәсе, гамәли белеме һәм энергиясе барлыгына ышандырырлык иде. Шунда ук иптәш Сибагатуллин хакимият башлыгы, шул ук вакытта депутатлыкка кандидат буларак та башкарасы эшләренең программасын бәян итте. Районның потенциаль мөмкинлекләре зур булуын ассызыклап, ул барлык тармакларда да планлаштырылган эшләрне әйтеп үтте.

Җыелышта депутатлыкка кандидатны яклап чыгыш ясаган район хатын - кызлар советы рәисе В.Г.Хоменко Ф.С.Сибагатуллинның хатын - кызларның тормыш - көнкүреш хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән сәясәтен хуплап, барлык хатын - кызларны да 30 нчы мартта депутатлыкка кандидатны яклап тавыш бирергә чакырды.

Очрашуның икенче өлешендә Ф.С.Сибагатуллин соңгы вакытта районның мәдәни тормышы җанлануын ассызыклап «Татарстан минем республикам» республика конкурсында призлы урын яулаган балалар музыка мәктәбе вокаль ансамбле (җитәкчесе Т.Бадыйгин), «Чуваш сандугачы - 97» республика фестивалендә лауреат исеме яулаган «Родник» чуваш халык җыры ансамбле (С.Ефремова), солистка И.Сафандеева, дипломант исемен яулаган, «Росинка» ансамблен (Н.Бочкарев), чуваш мәдәниятын торгызу һәм үстерүгә сак каравы өчен социаль яклау бүлеге начальнигы Л.Н.Дилмөхәммәтованы кайнар котлап, Мактау кәгазьләре һәм бүләкләр тапшырды.

Соңыннан республиканың танылган җырчысы, композитор Фирзәр Мортазин концерты булды.

Р.ГИНЯЕВА.

**Рәсемдә: Ф.С.Сибагатуллин Н.И.Бочкаревны котлый.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## *Җәйге вакытка күчәбез!*

**30 марттан 26 октябрьгә кадәр җәйге вакытка күчәбез. Русиядәге барлык сәгать телләре 30 мартта төнге сәгать 2дә бер сәгатькә алга күчерелә.**

## Хакимият башлыгы белән әңгәмә

# ТӘВӘККӘЛ, КЫЮ АДЫМНАР КИРӘК

***Узган ел Октябрь районы хакимият башлыгы итеп Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин билгеләнде. Ләкин зур нәтиҗәләр ясарга иртә әле. Алай да районда үзгәрешләр бара. Норлат төбәгенең киләчәген ничек күзаллый ул? Өстәлендә нидер исәпләп, санап утырган яңа җитәкчегә сорауларымны биреп өлгермәдем, үзе үк сүз башлады.***

- Менә бит, авылдан сөт - май комбинатына көн саен 57 тонна сөт керә башлаган. Былтыр ул 35 тонна гына булган. Тырышканда, эшләре бара бит егетләрнең! **(Бүген бу күрсәткеч 80 тоннадан артып китте инде.- Ред.)**

**Фатих Сәүбәнович күмәк хуҗалык җитәкчеләренең, белгечләренең, терлекчеләренең уңышы өчен чын күңелдән куансада, күп нәрсә район башлыгына бәйле. Халык мәнфәгатен кайгыртып йөрүен күреп, әүвәл район Советы рәисе постына сайладылар аны. Күптән түгел генә Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп тә күрсәттеләр.**

- Базар мөнәсәбәтләре, демократия хөкем сөргән заманда мондый зур ышанычны төпле эш - гамәлләрең белән ныгыта бармасаң, сиңа тиз суынулары, йөз чөерүләре ихтимал.

Менә хәзер республика парламентына депутатлыкка кандидат сыйфатында сайлаучылар белән еш очрашырга туры килә. Болай турыдан - туры сөйләшкәндә, әңгәмә корганда әллә никадәр җитди мәсьәлә күтәрә, тәкъдим кертә алар. Күреп торам, коры вәгъдәләр түгел, анык эш, иҗади, җанлы эш көтәләр үз вәкилләреннән.

***- Беренче мәлләрдә нинди проблемалар белән күзгә - күз очрашырга туры килде?***

- Әхлакый мохит, дисәм, дөреслеккә хилафлык кылмамдыр. Үзләре турында гына кайгыртучы эреле -ваклы түрәләрдән күңелләре кайткан халыкның, кемгә ышанырга да аптыраганнар. Шул гамьсезлек, битарафлык җирлегендә җинаятьчелек тамыр җәя. Яшүсмерләр арасында ул аеруча куркыныч төс алган. Бөтен җәмәгатьчелек белән катгый рәвештә тотынмаганда, әлеге ямьсез күренешләрдән тиз генә котылырга мөмкин түгел.

Авыл хуҗалыгындагы торгынлык та борчуга салды. Былтыр, мәсәлән, нибары 130 миллиард сумлык продукция житештерелгән. Күмәк предприятиеләрнең бурычы исә 118 миллиард сумнан артып ашкан. Димәк, авыл хуҗалыгы тармакларында тирәнтен үзгәреш, яңарыш таләп ителә.

***- Соңгы вакытларда агропромышленность комплексы структурасындагы үзгәрешләр шуның белән аңлатыламы? Элек башка чыккан күмәк хуҗалыклар яңадан күршеләре белән кушыла, икенчеләре эре предприятиеләр карамагына тапшырыла. Бу тагын чираттагы форма үзгәртү галәмәте генә түгелме?***

- Юк, һич юк. Аграр реформаны чын мәгънәсендә тормышка ашыруның хәлиткеч чаралары болар. Хәлдән таеп, тәмам бөлгенлеккә төшкән берише хуҗалыкларны яңадан көчлерәкләре белән кушарга мәҗбүр булдык. Ә менә аякларында нык басып торган биш хуҗалык, ит комбинаты белән берләшеп, дуңгыз ите җитештерүгә һәм эшкәртеп сатуга специальләшкән агрофирма оештырдылар. Фәкыйрьлеккә калган «Восход» күмәк хуҗалыгын шикәр заводы үз канаты астына алды. Әмма аны ярдәмче хуҗалык сыйфатында күрү түгел бу: авыл шәһәрдәге акционерлык җәмгыятенең тулы хокуклы әгъзасына әверелде. Инде мондый хезмәттәшлекнең уңай нәтиҗәләре дә күренә башлады: терлекчелек продуктлары җитештерү шактый арта төште. Үзәктән күпкә читтә урнашкан авыл - Торноястагы халык җир пае алып, аерым фермер хуҗалыклары булып яшәргә ниятләде. Пай дигәннән, «Заря», «Москва» күмәк предприятиеләрендә аны бүлеп бирү тәгәлләнде инде. Аларда хуҗалык итүнең башка төрле формасын сайладылар. Пайчылар кооперативка берләштеләр. Бу очракта нарядсыз, эчке хуҗалык исәбе белән эшләү күздә тотыла. Рәистән башлап һәркемгә түләү ахыргы нәтиҗәләргә карап. Кыскасы, хәзер хуҗалык итүнең берничә төре, формасы кулланышка керде. Реформаны башлаганбыз икән, кыюрак эшләргә туры киләчәк.

***- Фатих Сәүбәнович, соңгы елларда игенчелек һич тә куандырмый...***

- Бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 40 центнер ашлык алуны максат итеп куйдык. 30 центнерга да ирешмәгән килеш алай каты селтәнәсез түгелме, диючеләр табылыр. Тәвәккәллек, кыюлык күрсәтмичә, текә үрләргә омтылмыйча уңышка ирешеп булмый ләбаса. Минераль ашламалар белән чынлап торып эшләргә кирәк булачак. «Агрохимсервис» акционерлык җәмгыятенең базасын әнә шуны күздә тотып ныгыттык, киңәйттек. Сортлы орлык кайтару, алдынгы технологияне куллану үзен күрсәтер әле.

Шикәр чөгендеренең файдасыннан битәр зыяны күп, диләр. Чыны шул. Татлы тамыр җитештерүдән алынган табышның 23 - 27 проценты транспорт чыгымнарына киткәч, башкача мөмкин дә түгелдер. Аны рентабельле итү өчен һәр гектардан кимендә 300 - 350 центнер уңыш алырга кирәк.

Быел шикәр чөгендере плантацияләрен шикәр заводыннан 35 чакрымнан да ерак булмаган хуҗалыкларда гына урнаштырырга исәплибез. Сатудан кергән табышның 65 процентын татлы тамыр җитештерүчеләрнең үзләренә калдырырга (элек 55 процент) планлаштырабыз. Әлбәттә, бу очракта транспорт чыгымнарын да күмәк хуҗалыклар үзләре капларга тиеш булалар. Элек шикәр чөгендере игү белән шөгыльләнгән ерак хуҗалыклар бөртекле культуралар, барыннан да бигрәк, югары сыйфатлы, җилемсә бодай чәчәчәкләр.

***- Ел башында республика активы белән үткәрелгән бер киңәшмәдә Президент Татарстанның Россиядә кышын да үзенең халкын сөт ризыклары белән тәэмин итүче бердәнбер төбәк булуын әйтте. Моңа Октябрь районы терлекчеләре дә саллы гына өлеш кертәләр булса кирәк.***

- Сөт җитештерүдә берникадәр җанлану, алга китү бар. Былтыр бу күрсәткеч буенча район республикада 33 нче урында булса, хәзер 15 нче урынга күтәрелдек. **(Бүгенге көндә 8 нче.- Ред.)** Былтыргыга караганда һәр сыердан бер килограммнан да күбрәк продукция алабыз. **(Хәзер 2,5 килограммнан күбрәк.- Ред.)** Товарлылыгы ягыннан бүтән районнар арасында хәзер без 7 нче **(Бүген 1нче- Ред.)** урында. Базар икътисады шартларында табыш алуның кулай юлы бу. Кайчагында сыер асрап, сөт саву әллә ни керем бирми, дигән фикерләр ишетергә туры килә. Соң, файдасы юк, дип кул кушырып утырасыңмы инде? Терлек азыгы хәстәрләнгән, җаваплы кешеләре билгеләнгән, терлекчеләр үз урыннарында. Ничек булса да эшләргә, сөт җитештерергә, мая тупларга кирәк.

Ит җитештерүдә дуңгызчылыкны аякка бастыру бурычы тора. Әлегә ул шактый аяныч хәлдә. Әгәр 1986 елда район буенча дәүләткә сатылган итнең 37 процентын дуңгыз ите тәшкил иткән булса, былтыр шуның чирегенә дә җитмәгән. Ә бит «Рассвет» күмәк хуҗалыгы кебек эшләгәндә матур күрсәткечләргә ирешергә мөмкин. Сүз җаеннан, күптән түгел алдынгылар слетында терлекчелекнең бүгенге торышы, киләчәге турында төпле сөйләшү булды. Авыл эшчәннәре өчен зур бәйрәм рәвешендә үткәрергә тырыштык без аны. Авыл кешесе болай да кыерсытылган, кыен хәлдә хәзер. Аларга бирәсе хезмәт хакы гына да 11 миллиард сумга җыелган. Менә шуны крестьянга кайтарып бирәсе бар.

***- Халыкның тормыш - көнкүреш шартларын яхшырту, социаль мәсьәләләрне хәл итү буенча ниләр эшләнә?***

- Иң элек халыкка пенсия һәм пособиеләрне үз вакытында бирү җайга салынды. Байтак кына авылларга автобуслар йөри хәзер. Асфальт юллар салу, күперләр кору дәвам итә. Юл йөрүчеләр иң ерак торак пунктларына да барып җитәчәкләр. Һәрхәлдә райондагы ике юл төзү оешмасының эш күләме билгеләнгән һәм алар үз бурычларын үтәп баралар. Безне иң борчыганы - газ кертү мәсьәләсе. Бу эш моңа чаклы 23 процент чамасы гына үтәлгән килеш. 2000 елга кадәр күп кенә фатирны газлы итәсебез бар. 300 километрда газүткәргечләр сузарга кирәк. Элек районда моның белән махсус шөгыльләнүче оешма юк иде. «Норлатгаз» эксплуатация - производство идарәсе төзелде һәм үзенең эшчәнлеген әйбәт кенә башлап җибәрде.

***- Фатих Сәүбәнович, предприятиеләр, оешмалар уртак маяга үз өлешләрен тигез кертәләрме?***

- Юк шул. Салымнарның күләме кемнең ничек эшләвенә карый. Былтыр алар барлыгы 687 миллиард сумнан күбрәк продукция җитештергәннәр. Әмма шуның саллы өлеше - 84 проценты нефть һәм газ чыгару идарәсе коллективына туры килә. Ун предприятиенең бишесе генә продукциянең гомуми күләмен арттыруга ирешкән, калганнары киметкән. Болай булгач, артта баручы коллективларга да хезмәтне яңача оештыру турында уйланырга, үзәккә өметләнмичә үз көннәрен үзләре күрергә вакыт. Кайбер предприятиеләр мөстәкыйль эшләү юлын сайлыйлар. 53 нче төзү - монтаж идарәсе «Жилстрой» акционерлык җәмгыятеннән аерылып чыкты. Төрнәс спирт заводы да мөстәкыйль яшәүне кулай күрә.

***- Норлат кешеләренең теңкәсенә тигән су мәсьәләсен, ниһаять, ничек хәл итәргә уйлыйсыз?***

- Озак еллардан килгән су кытлыгын бер кизәнүдә генә хәл итү авыр, билгеле. Әмма быел җәй бу проблема хәл ителер дип, уйлыйбыз. Дала Мамыгы ягында ике өстәмә кое (скважина) казылды. Искеләре дә эшкә яраклы хәлгә китерелә. Чистарту корылмасының икенче чираты исә тиздән файдалануга тапшырылачак. Форсаттан файдаланып, шикәр заводы, тимер юл, нефтьчеләр микрорайоннарында урнашкан эре предприятиеләрне дә шәһәрне төзекләндерүдә аны тагын да ямьләндерүдә, халыкның көнкүрешен яхшыртуда да активрак булырга чакырыр идем.

***- Халыкка бит рухи азык та кирәк әле.***

- Кешеләрнең рухи саулыгын, мәдәният мәсьәләләрен һәрвакыт күз уңында тотабыз. Күп авыллардагы мәдәният йортлары, китапханәләр бер дә буш тормый. Район мәдәният йортында да төрле чаралар һәрдаим уздырыла. Районда чуваш әдәбияты атналыгы, күренекле композитор Сара Садыйкова көннәре, үзешчән артистларның республика смотры зур оешканлык белән үтте. Казан артистлары да безгә еш килә башладылар.

Хәзер Аллаһ йорты булмаган авылларны очратуы кыен. Мәчетләрнең яңалары ачыла. Норлатның үзендә берничә иман йорты эшли, тагын берсе төзелә. Тугандаш халыклар өчен чиркәү төзелеп бетте. Без гыйбадәтханәләр ачуга, аларның проблемаларын хәл итүгә игътибарны йомшартмыйбыз. Алар яшь буынны әхлакый тәрбияләүдә, иман нуры иңдерүдә зур эш башкара алалар. Хәзер анык кына идеология булмаган заманда бу аеруча мөһим.

**Әңгәмәдәш - И.ДИНДАРОВ.**

**(«Ватаным Татарстан»ның быелгы 22 март санынннан).**



**Н.АЗИЗОВ фотосында Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН сайлаучылар белән очрашуда.**

# 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

## ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ ӨМЕТЛӘНЕП

( Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Баксаң, аларны аграр сектордагы хәлләр дә бик кызыксындыра икән. Бу аңлашыла да, чөнки алар барысы да хәзер буровойлар калкып утыра торган шул җирдә үскәннәр бит, тамырлары шунда. Һәм район хакимияте башлыгына бирелгән сораулар да (алар барысы да турыдан - туры әйтелде) нефтьчеләрнең үзләренә генә хас мәсьәләләре хакында гына түгел, ә шәһәр һәм район масштабындагы гомумсоциаль проблемалар хакында иде. Сорауларда яшьләргә әхлак тәрбиясе бирү, эчүчелеккә каршы көрәш мәсьәләләре, «Родина» кинотеатрының, шәһәр бассейнының, культура һәм ял паркының язмышы кузгатылды, спорт - масса эше, район үзәгендә тротуарлар ясау, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү дәрәҗәсенә кагылышлы проблемалар күтәрелде. Ф.С.Сибагатуллин аларның һәммәсенә эшлекле, нигезләнгән ачык җаваплар бирде.

Очрашуда депутатлыкка кандидатның ышанычлысы - идарәнең профсоюз комитеты рәисе О.Н.Лизунов, скважиналарга капиталь һәм җир асты ремонты цехы инженер - технологы Р.Х.Әюпов, май культуралары эшкәртү участогы начальнигы Х.Г.Гафуров, идарә начальнигының капиталь төзелеш буенча урынбасары Т.М.Ильясов чыгыш ясадылар. Очрашуны НГДУ начальнигы М.М.Хуҗин алып барды. Җыелышта катнашучылар бу сайлауда Ф.С.Сибагатуллин кандидатурасын бердәм якларга җыенуларын белдерделәр. Һәм бу инде район халкы тарафыннан танылган җитәкче шәхесен яклау гына түгел, ә алга таба күп елларга күмәк эшчәнлек хакына тавыш бирү дә булачак.

**Т.НАЗАРОВА.**

***

***Узган шимбәдә шундый очрашу Якты Күл авылында узды.***

Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат Ф.С.Сибагатуллинның тормышы, эшчәнлеге, сайлау алды платформасындагы төп юнәлешләр белән хакимият башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова таныштырды. Җыелышта хуҗалык рәисе В.Сатдаров, пенсионер, ветеран С.Сатдаров кандидатның авылны үстерүгә, халыкның тормыш хәлен яхшыртуга зур игътибар бирүен билгеләп, республика дәрәҗәсендәге вәкаләт аңа тагы да зуррак мөмкинлекләр бирәчәген ассызыкладылар. Җыелышта катнашучылар сайлау көнне Ф.С.Сибагатуллинны яклап тавыш бирәчәкләрен әйттеләр.

- Безнең кеше ул, авыл халкын аңлый да, хөрмәтли дә белә, аңа ышанырга була,- диделәр. Хәзер авылларына зәңгәр ягулык килүен зур түземсезлек белән көтүләрен әйттеләр.

Соңыннан күптармаклы җитештерү предприятиесе концерт бригадасы зур концерт күрсәттеләр.

## Һичшиксез яклаячакбыз!-

дип, бердәм фикер белән тәмамланды Норлат автоюллар идарәсендә узган сайлау алды җыелышы. Идарә начальнигы Һ.Х.Садыйков коллектив членнарын депутатлыкка кандидат Ф.С.Сибагатуллинның тормышы һәм хезмәт юлы, район җитәкчесе буларак башкарган һәм башкарасы эшләре белән таныштырды. Идарәнең профком рәисе Л.Г.Тимофеева, асфальт түшәү машинасы машинисты А.Голубев 30 март - сайлаулар көнне үз тавышларын Ф.С.Сибагатуллинга бирәчәкләрен белдерделәр, алар фикере тулаем коллективта хуплау тапты.

**Базар**

## Әүвәл сертификат сора

Соңгы елларда шәхси сәүдә киңәю кулланучылар базарын төрледән - төрле товарлар белән баетырга мөмкинлек бирде. Базар прилавкаларында азык - төлектән генә дә җаның ни тели - шуны алырга була. Әмма ашыкмагыз! Матур - матур төргәкләрдә, ялтыравыклы тартмаларда җиде җир читеннән кайтарылган, төс - кыяфәтләре белән авыздан сулар китерерлек нигъмәтләр ашарга яраклымы? Ул сәламәтлеккә зыян белән янамыйммы? Һәр сатып алучы кесәсенә акчага үрелгәнче шул хакта уйлансын һәм сатучыдан товар сертификатын күрсәтүен сорасын. Сыйфат сертификаты - продукциянең әйләнә тирә, тормыш, сәламәтлек, милек өчен куркынычсызлыгын контрольдә тотучы, продукциянең сыйфат күрсәткечләрен дәлилләүче документ ул. Сатучы үзендә сертификатның төп нөсхәсен яки тиешле рәвешле расланган сертификат копиясен булдырырга тиеш. Еш кына без тикшерү вакытында берничек расланмаган сертификат пачкаларына гына тап булабыз. Ул гамәлгә яраклы түгел. Сертификат төп нөсхә иясе яки нотариус, яисә госстандартнадзорның территориаль органы тарафыннан расланырга тиеш. Сатучыда шулай ук сертификатның төп нөсхәсе яки тиешенчә расланган копиясе нигезендә төзелгән товар озату документлары да булу шарт. Товар - транспорт накладноенда сертификат турында мәгълүматлар товар җитештерүче яки поставщикның имзасы һәм мөһере белән расланырга, соңгысының адресы һәм телефоны күрсәтелергә тиеш.

Сәүдә итүче оешмалар, эшмәкәрләр һәм кулланучылар тагы бер нәрсәне белергә тиешләр: 1996 елның 27 декабреннән Россия Федерациясенең «Россия Федерациясенә кертелә торган ашамлык продуктларында рус телендә мәгълүмат булуны тәэмин итүче карарларны раслау турында»гы карары кабул ителде. Аның нигезендә 1997 елның 1 маеннан Россия Федерациясе территориясендә рус телендә информациясе булмаган чит ил ашамлыклары сату тыела. Бу чара республикага сыйфатсыз азык - төлек кертелүне тыю һәм безгә аңлаешлы телдә мәгълүматлар бирүне күздә тотып эшләнә.

Бу кагыйдәләр бүген генә дөньяга килмәгән, ул сату итүчеләр өчен иң төп таләпләрдән санала. Шуңа карамастан, безнең даими рейдлар вакытында аларны үтәмәү очраклары очрап торалар. Әйтик, 12 февраль көнне Кошки районыннан шәхси эшмәкәр В.И.Яфановның ысланган скумбрия, тозланган горбуша һәм сельд балыкларын сыйфат сертификатыннан башка сатуы мәгълүм булды. Товар санитар кагыйдәләрне үтәмичә, җирдән сатыла иде. Шундый ук хәл шәхси эшмәкәр Р.Р.Зубковада да күзәтелде. Ул чикләвек, өрек, йөзем һәм Самара шоколадларын сертификатсыз гына сатарга җайлашкан, өстәвенә, товар янәшәлеге кагыйдәләрен дә үтәми. Әлбәттә, без әлеге иптәшләргә карата тиешле чараларны күрдек. Әмма андый очракларны булдырмау өчен сезнең дә уяулык, үз сәламәтлегегезне кайгыртуыгыз кирәк. Шуңа да, кабат исегезгә төшерәбез: базардан товар алганчы, иң әүвәл сыйфат сертификатын сорагыз. Шул чакта ризыгыгыз тәмле генә түгел, куркынычсыз да булыр.

**Р.СУФИАНОВ,**
**кулланучылар хокукын яклау буенча Октябрь район комитеты рәисе.**

## Терлекчелек - көнүзәк өлкә

## Көтүнең артуын көтеп кенә булмый

моның өчен хуҗалыкларда бу юнәлештә көндәлек даими эш алып барырга кирәк. Моннан элек, терлекчелектә ике айлык эш нәтиҗәләрен анализлауга багышлап «Үрнәк» хуҗалыгында уздырылган семинар - киңәшмәдә ул хакта бик ачык итеп әйтелде. Көтүне яңарту, маллардан, аерым алганда сыерлардан тотрыклы үрчем алуның мөһим факторларыннан бу хуҗалыкта терлекләрне ясалма орлыкландыру эшенең яхшы оештырылуы турында әйтелде, анысы фермадагы ясалма орлыкландыру пунктының да, малларга барьяклап төгәл учет алып бару журналларының да тиешле тәртиптә булуы белән раслана иде. Узган атнада көтүне яңарту буенча технологларның (элеккечә әйтсәк, ясалма орлыкландыру техникларының) уку - киңәшмәсендә бу хакта тагын да җентекле сүз булды.

Ул мәсьәләгә шулай аерым игътибар бирелү һич тә юкка түгел. Сөт җитештерүне арттыру һәм моңа беренче чиратта малларның продукт бирүчәнлеген күтәрү юнәлешендә соңгы берничә айда ирешелгән үрләрдән чигенмик дисәк (ә бүген район буенча бер сыердан уртача көнлек савым 9 килограммга якынлашып килә), алга таба һәр хуҗалыкта сыерларның нәсел сыйфатларын яхшырту һәм көтүне яңарту юнәлешендә җентекле эшләргә кирәклеге бәхәссез. Соңгысы беренче чиратта үрчем алу һәм бозаулаган сыерларны вакытында каплату мәсьәләсенә кагыла. Шөкер, быел күпчелек хуҗалыклар бу ике юнәлештә дә эшне уңышлы алып баралар. Шуның нәтиҗәсе буларак, ике айда район буенча узган елның шул чорындагыдан 324 башка күбрәк бозау алынды. Шунысы куанычлы, бозаулаган сыерларның күпчелеге үзвакытында каплатылды һәм шулай итеп 1997 елда бозау алу программасын уңышлы үтәүгә ышанычлы нигез салынды. Мичурин исемендәге, «Кондырча»,»Мамык», Якты Күл, «Восход», «Үрнәк» хуҗалыкларында быел сыерлардан үрчем дә аннан алдагы елдагыдан шактый күп алынды, бозаулаган сыерлар да нигездә үзвакытында каплатылды. «Алга»да савым көтүен мул продуктлы таналар белән тулыландыру юнәлешендә зур эш башкарылды һәм бүген ул таналардан үрчем алына инде. Соңгы вакытта «Заветы Ильича» КХАсында да маллардан сәламәт үрчем алып аның яхшы сакланышына ирешү буенча эшнең нәтиҗәсе күренә.

Ул эшне моннан ары да да йомшартмаска кирәк. Кызганычка каршы, көтүне яңарту юнәлешендә эш бик начар куелган хуҗалыклар да бар әле. Хафизов исемендәге, «Родина», «40 лет Победы», «Сөлчә», «Таң» хуҗалыкларында бозау алу да былтыргыдан азрак әлегә, өстәвенә, бозаулаган сыерларны кабаттан каплату эше дә артта кала. Телгә алынган хуҗалыкларның соңгы икесендә ясалма орлыкландыру пункты да, көтүне яңарту буенча технологлар да булмаган шартларда бу гаҗәп тә түгел. Шуңа да район буенча быел бозаулаган сыерлар белән каплатылган сыерлар арасындагы аерма 200 баш тирәсе дә инде. Һәм ул аерманы мөмкин кадәр киметү өчен һәр хуҗалыкта нәтиҗәле эш оештырылырга тиеш. Көтүне яңарту буенча технологларның алда телгә алынган уку - киңәшмәсендә нәкъ менә шул уңайдан алар алдында торган җитди бурычлар турында сүз барды. Алар алдында нәсел эше буенча дәүләт инспекторы Р.С.Гыйлаҗев,район авыл хуҗалыгы идарәсенең терлекчелек буенча баш белгечләре чыгыш ясадылар. Шунда ук технологларны аттестацияләү дә уздырылды.

**Р.МУЛЛИН.**

## Икесе дә уңганнар

Әкълимә Шиһапова һәм Гөлсем Сәлахованың исемнәре газета укучыларга яхшы таныш. Алар «Татарстан» КХА фермасында күп еллардан бирле сыер савалар. Тәҗрибәле савучылар, үз эшләренең осталары, хезмәтләрен җиренә җиткереп икесе дә булсын дип эшлиләр. Икесе дә беренче кат бозаулаган яшь таналарны савалар. Һәм, әйтергә кирәк, сөт муллыгы өчен көрәштә алгы сафта баралар. Күрсәткечләре әйбәт булгач, кәефләре дә күтәренке. Эш урыннары һәрвакыт ялт итеп җыелган, сыерлары чистартылган. Хуҗалык җитәкчеләренең алар турындагы фикерләре дә гел уңай. Яраткан эш ялыктырмый диләр бит. Шуңа да күпме еллар бу авыр хезмәтне башкарсалар да, аларның беркайчан да үз эшләреннән зарланганнарын ишетмәссең. Рәсемнәре елның - елында колхозның мактау тактасыннан төшмәде. Күп еллар эшләү дәверендә күпме Мактау кәгазьләре, кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнеп килделәр. Быел колхозның отчет - сайлау җыелышында колхоз савучылары арасында беренче урынга чыккан өчен Әкълимә Шиһапова колхоз идарәсе тарафыннан акчалата премия белән бүләкләнде. Ә үткән ел бу бүләккә Гөлсем Сәлахова лаек булган иде. Билгеле, тырыш хезмәт нәтиҗәсе бу. Фермада гына түгел, үз хуҗалыкларында да уңган хатыннар алар. Йорт тотып мал - туар асрыйлар.

Хәзерге көндә бу уңганнар үз группаларындагы яшь маллардан көнгә уртача 12,5 - 13 килограмм сөт алуга ирешәләр. Менә шулай хезмәтләреннән тәм табып эшлиләр алар. Уңышлар сезгә, хезмәттәшләр!

**З.ИСМӘГЫЙЛЕВА.**
**Кычытканлы авылы.**

**М**иллəт
**М**əгариф
**М**əдəният
**М**əгърифəт

# ТИГЕЗ ГОМЕР ТЕЛИЛƏР

Безнең Г.Кариев исемендəге мəдəният йортында берсеннəн берсе кызыклы чаралар үткəрелə. Шушы көннəрдə озак еллар Колбай Мораса мəктəбендə тəрбияче, соңгы елларда балалар бакчасында мөдир булып эшлəгəн Рəйсə Хатыйп кызы Галиуллинаны лаеклы ялга озату тантанасы булды. Бөтен гомерен балалар тəрбиялəүгə багышлаган хезмəт ветеранын котларга хезмəттəшлəре, дуслары килгəн иде.

Юбилярны Колбай Мораса җирле үзидарə Советы рəисе Альберт Ибраһимов чын күңелдəн котлады һəм истəлекле бүлəк тапшырды.

Рəйсə ханым шушы авылда туып - үсеп, урта мəктəпне тəмамлады. Матур итеп үрнəк гаилə корып җибəрде. Рамил Галиуллин белəн 5 бала тəрбиялəп үстерделəр. Олы кызлары Рамилə əнисенең һөнəрен сайлады. Казан педагогия институтын тəмамлады, Раилə Чистай шəһəрендə медицина хезмəткəре белгечлеге алды, бүгенге көндə балалар дəвалый. Ə өч балалары урта мəктəптə белем алалар. Рамил белəн Рəисə эти - əнилəрен, авыру апаларын карап - тəрбиялəп соңгы юлга озаттылар.

Тату Галиуллиннар эшкə дə, ялга да өлгерлəр. Мəдəният йортында үткəн концертлар алардан башка узмый. Авылдашлары Рəйсə белəн Рамилнең биюлəрен яратып һəм сокланып карыйлар, «Матур парлар, бəхетле ярлар» дип, олыгайган көннəрендə дə тигез гомер кичерүлəрен телилəр.

**Т.МИНГƏРƏЕВА,**
**китапханə мөдире.**

# ЯШЬТƏН БАШЛАУ ЗАРУРИ

*Мəгариф*

Экологик тəрбия укучыларда тирə - юнь мохитка сакчыл караш, табигатькə, кешегə, хайваннарга мəхəббəт тəрбиялəү ул. Ə балаларны бу юнəлештə никадəр иртəрəк тəрбияли башлыйсың, шулкадəр яхшырак. Күптəн түгел шəһəрнең беренче урта мəктəбендə районның башлангыч класслары укытучыларының «Башлангыч класслар укучыларына экологик тəрбия бирү» темасына үткəн семинары көн тəртибенə дə шул мəсьəлə кертелгəн иде.

Билгеле инде, семинар үткəрү җиңел эш түгел. Мəктəбебез укытучылары да бу җитди чарага күңел биреп хəзерлəнделəр. Аерым алганда, мəктəп директорының башлангыч класслар буенча урынбасары Лидия Михайловна Лукашенко бу юнəлештə күлəмле эш башкарды.

Семинар үтə эшлекле шартларда барды. Анда катнашучылар укытучы - методист Вера Анатольевна Одинцованың рəсем, Екатерина Ильинична Казаеваның табигать белеме буенча үткəргəн дəреслəрен аеруча ошаттылар. Əйдəп баручы укытучы Фəния Əбделхəеровна Даутова исə «Табигать һəм без» дигəн класстан тыш чара үткəрде. Семинарда катнашучылар рəсем дəресенең җыр дəресе белəн отышлы интеграциялəнүен бəялəп, моның сəнгатькə мəхəббəт тəрбиялəү, эстетик зəвык, иҗади күзаллауны үстерүдəге ролен ассызыкладылар. Күргəзмə материалларның кырга мавыктыргыч сəяхəтен күзалларга ярдəм итүе, шул рəвешле авыл эшчəннəренең анда нинди культуралар үстерүе, кайсы корткычлар, бөҗəклəр белəн көрəш алып барырга кирəклеген белделəр. Гомумəн, балалар табигать турында байтак файдалы һəм кызыклы əйберлəр ишеттелəр. 2 нче б классында үткəн «Табигать һəм без» класстан тыш чарасында укытучылар уен - сəяхəтне, урман алаunion концертны, пресс - конференцияне дə ошаттылар. Шунысын да əйтергə кирəк, чара башыннан азагына кадəр музыка астында барды. Балалар рəхəтлəнеп җырладылар, сөйлəделəр, биеделəр. Һəм чарадагы һəр моментта Татарстан, яраткан шəһəребез Норлатка, мəктəбебезгə мəхəббəт белəн сугарылган иде. Шул ук вакытта укытучының бөтен яклап биргəн талантына да игътибар бирелде: Фəния Əбделхəеровна, мəсəлəн, шигырь, көй яза, рəсем ясый, сценарийлар төзи, стендлар ясый, үзе үк күргəзмə материаллар да хəзерли.

Семинарның теоретик өлешендə Валентина Михайловна Шумарина сөйлəгəн доклад та кече яшьтəге мəктəп укучыларына экологик тəрбия бирү проблемаларын тулысынча ачып салды. Ул мисалларга да бай иде. Ирина Петровна Гатауллина исə бу проблеманы хəл итүдə үзе ясаган күргəзмə əсбаплар, аларны ничек итеп дəрестə файдалануы турында аңлаешлы итеп сөйлəде. Гомумəн, педагогның бу юнəлештə туплаган бай тəҗрибəсе яшь укытучылар өчен яхшы ярдəмлек булыр иде.

Йомгаклау сүзе белəн чыгыш ясаган район мəгариф бүлеге мөдире О.С.Тарасова семинарда фикердəшлəрнең очрашуын ассызыклап, əлеге чараның югары дəрəҗəдə үтүен һəм анда катнашучыларның педагогик осталыгы камиллəшүенə тагын бер адым буласын билгелəде.

**З.АПЫШКОВА.**

# БАЛА ШАТЛЫГЫ - БЕЗГƏ КУАНЫЧ

Балалар - безнең якты киләчәгебез. Шуңа да без «Кыңгырау» балалар бакчасы хезмәткәрләре балаларыбыз сау - сәламәт, бәхетле булып үсеннәр өчен көчебездән килгәннең барысын да эшлибез. Бакчада һәртөрле бәйрәмнәр, күңелле, мавыктыргыч чаралар, уеннар үткәрәбез. Нәкъ шуларда балаларның мөмкинлекләре, сәләтләре ачыла, ул халык гореф - гадәтләре белән таныша, аларга якыная. Әле менә март башында, язгы кояшлы көннәрнең берсендә берсеннән - берсе тырышып бизәнгән - ясанган балалар җырлар, биюләр, шигырьләр белән урамга кышны озатырга һәм ямьле язны каршы алырга чыктылар. Алар янына кунакка алсу йөзле Майлыбикә килде. Гадәт буенча балаларга кайнар коймаклар әзерләнгән иде. Кунакны уртага алып җырлар башкарылды, аннары уеннар, аттракционнар үткәрелде. Балалар ул уеннарда зур канәгатьлек белән катнаштылар. Аларның күңелле кәеф тудыра белүенә, хәтта олыларны да шатландыра алуына без чын күңелдән сөендек. Хәер, безнең эшебезнең дә төп мәгънәсе нәкъ шунда бит: балалар шатланса - безгә дә зур куаныч.

**Н.МАЛИКОВА,**
**тәрбияче.**

**Рәсемдә: бәйрәмнән бер күренеш.**



# КОТЛЫЙБЫЗ

*ОСТО район комитеты рəисе*
***Дамил Җəмил улы Бикиевны***
*туган көне белəн котлыйбыз.*
*Котлап сине туган көнең белəн*
*Без телибез сиңа ак бəхет.*
*Килəчəгең якты, матур булсын,*
*Шатлык юлдаш булсын һəрвакыт.*
***Хезмəттəшлəре.***

Салдакай авылында яшəүче кадерле тормыш иптəшем, əтиебез, дəү əтиебез **Дəүлəтша Фəйзрахман улы Мостафинны** туган көне белəн котлыйбыз.

Яшəү маягы син безнең өчен,
Кешелегең белəн үрнəк син.
Мең - мең рəхмəт тəрбияңə, эти,
Безнең өчен һəрчак кирəк син.
**Тормыш иптəшең, балаларың, оныкларың.**

# БЕЛДЕРҮЛƏР

## Сатабыз

**Пушкин поселогы янында 4,5 сутыйлы дача участогы (кирпеч йорты, коесы бар).** Адрес: Октябрьская ур., 34 (кичке 4тəн соң).

***

**Яңа «Урал» мотоциклы**. Зирекледə тел.: 3 - 52 - 74.

***

**Яңа газ плитəсе.** Тел.: 5 - 21 - 94.

***

**Яңа «Кассио» япон синтезаторы.** Тел.: 5 - 21 - 27 (кичке 6дан 9га кадəр).

***

**Полевая ур., 18 адресы буенча йорт.** Тел.: 2 - 17 - 50 (иртəнге 8дəн кичке 6га кадəр).

***

**Калинин урамында йорт.** Советская ур., 139 - 5 адресы буенча кичке 6дан соң Калашниковларга мөрəҗəгать итəргə.

***

**Əйбəт хəлдəге, җəелə торган өстəл, «Свияга» суыткычы, газ колонкасы ( Польшада чыккан, ак төстə, төргəн көе), шифоньер, сервант**. Адрес: Школьная ур., 11-12, тел.: 2 - 29 - 04.

***

**Ике бүлмəле фатир, кыйммəт түгел.** Тел.:34 - 2 - 14.

***

**Южная ур., 21 адресы буенча йорт.** Ленинградская ур. 19 - 4 адресы буенча мөрəҗəгать итəргə.

***«Надежда» дəүлəт предприятиесе (КБО) бер елга гарантия белəн 1.900.000 сумга «Полюс» суыткычлары сата.***
***Модалар ательесында,***
***көнкүреш хезмəте күрсəтү йортында (чəчтараш),***
***шикəрчелəр поселогындагы көнкүреш хезмəте күрсəтү йортында һəм***
***авылларда кабул итү пунктларында***
***кабул итүчелəргə мөрəҗəгать итəргə.***

**Тимер юл вокзалы территориясендə һəр көнне иртəнге 7дəн төнге 11гə кадəр «Встреча» яшьлəр кафесы эшли. Төрле чаралар үткəрүгə заказлар кабул ителə.** Тел.: 2 - 18 - 76.

**Бакыр, җиз, бронза, мотор һəм электр алюминие калдыклары кабул итəбез.** Тел.: 5 - 21 - 94.

***Казанның «Заря» кондитер фабрикасы белəн Норлат - Октябрь сəүдə базасы арасында дилерлык нигезендə бергəлəп эшлəү турында шартнамə төзелде. База складыннан фабриканың түмəрлəп озату бəялəрендə киң ассортиментта кондитер əйберлəре алырга була. Товар алып реализациялəүгə килешү төзергə дə мөмкин.***
Белешмəлəр өчен тел.: 2 - 28 - 90, 2 - 27 - 81.

# Холкың нинди?

Японнар фикеренчə, кан группасы кешенең холкын һəм аерым сəлəтлəрен ачып бирə икəн.

**I группа.** Лидер булырга омтыла. Максат куйса, телəгенə ирешкəнче тырышачак. Алга бару юлын сайлый белə. Үз көченə ышана. Хисле. Йомшак яклары да бар: көнлəшүчəн һəм масаючан.

**II группа.** Гармония, тынычлык һəм тəртип ярата. Кешелəр белəн яхшы аралаша. Сизгер, сабыр һəм игелекле. Йомшак ягы - үзсүзле һəм ял итə белми.

**III группа.** Ачык күренеп торган «шəхес». Үзенə ничек ошаса, шулай эшли. Бөтен нəрсəгə дə җиңел җайлаша. Лəкин бəйсез булырга телəве кайбер чакта артып китə һəм йомшаклык күрсəтə.

**IV группа.** Тыныч һəм сабыр холыклы. Кешелəрне ярата һəм алар белəн үзен яхшы хис итə. Мавыктыра белə, тирə - юньдəгелəргə карата əдəпле һəм гадел. Кайбер чакта зəһəр, өстəвенə, кирəк вакытта тиз генə карар кабул итə алмый.

**(«Шəһри Казан»нан).**

БАШ МӨХƏРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХƏРРИР **С.Н.ХƏЙРУЛЛИНА**

**Учредительлəр: Октябрь район хакимияте һəм редакциянең хезмəт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чəршəмбе, җомга, шимбə көннəрендə чыга, рус һəм чуваш теллəренə тəрҗемə ителə.**

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шəһəре, Карл Маркс урамы,19.
Телефоннар: баш мөхəррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхəррир һəм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һəм җəмəгать оешмалары тормышы, чуваш теленə тəрҗемə буенча мөхəррир - 2-10-44, җаваплы сəркəтип - 2-18-67, рус теленə тəрҗемə буенча мөхəррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мəгълүмат һəм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белəн теркəлде.*

Ульяновск өлкəсе матбугат һəм мəгълүмат идарəсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белəн басылды. Күлəме - 1 басма табак. Тираж 2047 данə. Заказ N 6032.